ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 г.Лениногорск № 1158

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 22 февралендәге 811 номерлы карары белән расланган Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында»2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясын гамәлгә ашыру максатларында, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру мәсьәләсе буенча 2022 елның 28 октябрендәге 7 номерлы мөрәҗәгатьләрне карау буенча комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 22 февралендәге 811 номерлы карары белән расланган Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны һәм муниципаль берәмлек территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын массакүләм мәгълүмат чараларында Лениногорск шәһәре - Лениногорск муниципаль районының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://Leninogorsk.tatarstan.ru батырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Г.А. Ивановага йөкләргә.

Җитәкче З.Г. Михайлова

Куприянова О.В.
5-45-80